**ХӘЗЕРГЕ ДӘРЕС**

**ДӘРЕСНЕ ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮ**

**М. МӘХМҮТОВ, академик**

Мәгълүм ки, дәрескә өч җәһәттән: укыту процессын оештыру формасы («дәрескә таләпләр», аны «классификацияләү»; «структурасын билгеләү» һ. 6. шундый төшенчәләр ярдәмендә); укыту процессын оештыру методикасы (яңа материалны өйрәнү, белем һәм күнекмәләр үзләштерү, дәрестә индивидуаль якын килү, күрсәтмәлелек куллану, ягъни укыту методларын һәм *алымнарын* куллану һ. 6.) итеп һәм, ниһаять, форма белән методларның бергә үрелеп барылуы дип карарга мөмкин. Башта без дәреснең беренче җәһәтенә күбрәк тукталган идек, чөнки дәрес теориясенең төп төшенчәләрен (типология, структура һ. б. ш.) аңлатуга яңача якын килүнең асылын ныграк яктыртырга кирәк иде. Шулай да, дәреснең төп өлешләренең (компонентларының) эчтәлеген яңача аңлатуның әһәмиятен күрсәтү өчен, хәзер аның методикасының төп моментларына тукталып узыйк. Әлбәттә, укытуның барлык методлары һәм ысуллары да бер дәрестә кулланыла алмый, алар бер-берсенә тоташып барган дәресләр системасында файдаланыла.

Гадәттә, дәреснең башы, барышы һәм азагы турында сөйлиләр. Бу өч өлешнең тоташ барышы — процесс ул. Димәк, бу — дәреснең билгеле бер этапларының, структурасы компонентларының чикләрендә төрле-төрле *методлар* куллану дигән сүз. Укыту процессы хосусый методикаларда шактый тулы яктыртылса да, башта — укыту процессын оештыру ысулларына, ә аннары дәреснең төрле этапларында ал арның ничек кулланылуына тукталырга булдык.

Укыту процессында укытучы төп өч гомуми функцияне (вазифаны) үти: укучыларга яңа материалны бәян итә, яңа материалны үзләштерү буенча алар-ның мөстәкыйль эшен оештыра, уку процессына контроль ясый, ягъни шул процесс белән идарә итә.

Яңа материалны бәян итү ике төрле дәрәҗәдә: хәбәр итү (информацион) һәм проблемалы бәян итү рәвешендә *булырга* мөмкин. Беренчесендә укытучы практикада киң таралган «монологик» *(ягъни* үзе генә сөйли) укыту методын куллана (ул сөйли, аңлата, укучылар тыңлыйлар, күзәтәләр, ятлыйлар). Проблемалы бәян итү укытуның катлаулырак төре булып тора; ул укытуның өч гомуми методы ярдәмендә тормышка ашырыла:

а) «күрсәтмәле» метод кулланганда укытучы фән тарихында барлыкка килгән фәнни проблемаларны һәм галимнәрнең аларны чишү ысулларын (сөйләп) күрсәтә, яки шул фәнни һәм практик проблемаларны (өйрәнелә торган материал нигезендә) ул үзе әйтә (тәкъбир итә) һәм, төрлечә фараз итеп һәм аларны исбатлый-исбатлый, тәкъбир ителгән проблемаларны чишү ысулларын аңлата; укучылар игътибар белән тыңлыйлар (проблемалы ситуация акыл читенлеге буларак «эчке диалогны» активлаштыра), аларның тема белән кызыксынуы көчәя, укучылар материалны *тиешенчә* эмоциаль фонда үзләштерәләр;

*б)* «диалогик» метод яңа *материалны* хәбәр итү рәвешендәге әңгәмә ярдәмендә бәян итүдән гыйбарәт; укытучы
проблемалы сораулар куя, аларга үзе җавап бирә, бу вакытта укучылар да укытучы куйган проблеманы чишү юлларын эзлиләр һәм үзләре дә сорау-җавап бирәләр;

в) «эвристик» метод та диалог кебек, ләкин ул эвристик әңгәмәнең проблемалы мәсьәләләр (бурычлар) куелу белән бергә кушылуыннан, үрелеп баруыннан гыйбарәт: яңа материалның бер өлешен укытучы танып-белү бурычлары һәм мәсьәләләре рәвешендә тәкъдим итә, икенче өлешне укучылар, проблемалы сораулар һәм мәсьәләләрне чишә-чишә, үзләре мөстәкыйль рәвештә үзләштерәләр. Монологик методтан эвристик методларга күчә барган саен укытуның проблемалылык һәм укучыларның танып-белү

мөстәкыйльлеге дәрәҗәсе арта төшә. Бу күп кенә факторларга, әмма, нигездә, укыту методларын[1] сайлап алуга йогынты ясый торган факторларга бәйле.

Яңа материалны бәян итүнең әлеге төрләрен кулланганда, укытучы күрсәтмә әсбаплардан, аудиовизуаль техникадан файдалана, уен рәвешендә төрле ситуацияләр барлыкка китерә ала. Алар дәреснең төп өч этабының теләсә кайсында— белемнәрне актуальләштер-гәндә, яңаларын үзләштергәндә, алар-ны гамәлгә куйганда, ягъни практикада кулланганда булырга *мөмкин.* Мәгълүм ки, һәр материалны да проблемалы рәвештә бәян итеп булмый, кайчакта алай эшләүнең кирәге дә чыкмый. Иң әһәмиятлесе — укучыларның мөстәкыйль эшләрен оештырып, укытуны активлаштыру. Мөстәкыйль эшләрне оештыру укытучы өчен шактый катлаулы һәм, дәреснең максатына, укучыларның укытылу — тәгълим һәм укытучының методик осталык дәрәҗәсенә карап, алар барлык тип дәресләрдә һәм аның теләсә *ft* кайсы этабында кулланыла. Мөстәкыйль эшләрнең проблемалылык дәрәҗәсе, типлары һәм төрләре төрлечә: башкару характерында, ярым иҗади, иҗади, конструктив-техник һ. б. булырга мөмкин (карагыз: М. И. Мах-мутов. Проблемное обучение. М., 1975).

Әлбәттә, *югарыда* әйтелгән факторларга бәйле рәвештә, яңа материалны укытучының сөйләп аңлатуы белән мөстәкыйль эшләрнең нисбәте төрлечә була.

Укытуның репродуктив (монологик, алгоритмик һ. б.) методлары үзенә бер төрле ысуллар (сөйләм, хәбәр итүле әңгәмә, типик мәсьәләләр, күнегүләр эшләтү, эшләү үрнәген күрсәтү һ. б.) белән, продуктив (диалогик, күрсәтмәле, эвристик, тикшерү-эзләнүле) методлар башка ысуллар (проблемалы лекция, *проблемалы ситуацияләр* барлыкка китерү һәм проблемалы танып-белү мәсьәләләрен чишүне оештыру, укучыларның эксперименты һ. б. ш.) белән тормышка ашырыла.

Дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрү ысулларының берсе — укытучының методларны оста чиратлаштыра, төрләндерә белүе. Ә бу исә өйрәтеләсе материалның эчтәлеген өлешләргә дөрес бүлүгә һәм укытудагы кирәкле алым-, нарны, ысулларны сайлый белүгә бәйле. Укыту методлары системасы укытучының һәм укучылар эшчәнлегенең барлык төрләрен дә үз эченә ала; дәрестә дискуссияләр, уеннар, укучыларның лаборатор һәм практик эшләрен, тәҗрибә һәм эксперименталь эшләрне оештыру да җитди роль уйный.

Табигый, дәреснең *нәтиҗәлелеге* аңа ничек әзерләнүгә, дәреснең планына, укыту методларының ничек сайлап алынуына бәйле. Ләкин ул болар белән генә чикләнми, практика күрсәткәнчә, дәрес башлану белән үк, укыту һәм уку процесслары үзара тәэсир итешә башлый, билгеле бер психологик атмосфера (берәр төрле «кәеф» кебек нәрсә) барлыкка килә, максатлар, мотивлар, кәефләр капма-каршылыгы килеп чыгарга мөмкин. Шуңа күрә укытучы, үзенең профессиональ осталыгына, белем һәм тәҗрибәсенә таянып, дәресне нәтиҗәле, яки, киресенчә, укытучының үзенә дә, укучыларга да кызыксыз, уңышсыз итә торган барлык факторларны да алдан ук белеп-сизеп торырга тиеш. Укыту методларын дөрес сайлап алу һәм оста чиратлаштыру, тәрбия методларыннан уңышлы файдалану, йомшак өлгерүчеләргә теләсә кайсы моментта ярдәм итәргә әзер булу, аларда үз көчләренә ышаныч тудыру, эшкә дәрт уяту, элеккечә авторитар (мәҗбүр итеп эшләтү) түгел, ә демократик стильдә (В. Ф. Шаталов, Е. Н. Ильин, И. Х. Бикбулатова тәҗрибәләрендәге кебек) эш итү — болар барысы да дәреснең яхшы сыйфатлы булуы өчен мөһим шарт булып тора (карагыз: Р. Х. Шакуров. Директор школы и микроклимат учительского коллектива. М., «Знание», 1979. № 3). Югарыда санап узылган укыту эшчәнлеге һәм уку эшчәнлеге дәреснең барлык этапларында: белемнәрне актуаль-ләштергәндә, яңа материалны үзләштергәндә һәм практикада кулланганда баштан алып ахырынача дәвам итә.

---

[1] Уку-укыту методларын без еч төрле итеп аңлатабыз: аларны теория итеп караганда — дидактик методлар дибез (монологик, күрсәтмәле, диалогик, эвристик, эзләнүле алгоритм һәм программалаштыру методлары); методика дәрәҗәсендә уку һәм укыту кагыйдәләре (аңлату, дәртләндерү, эзләнү һ. б. методлар) һәм технология дәрәҗәсендә конкрет алым, ысуллар итеп аңлатабыз (мәсәлән, хәбәр итү, сорау кую, бирем бирү, фильм күрсәтү, мәсьәлә чишү һ, б. ш.).

1. Терәк белемнәрне һәм эш-гамәл ысулларын актуальлэштерү, гадәттә дәрес башында була һәм дәреснең ничек узуына нык йогынты ясый. Дәресне башлап җибәрүдәге шикелле, белемнәрне актуальләштеру алымнары да күптәрле. Дидактик һәм методик әдәбиятта, мәсәлән, «оештыру моментының», белемнәрне, өйгә эшнең үтәлешен тикшерүнең ничек булырга тиешлеге шактый тәфсилләп тасвирланган. Бу, әлбәттә, яшь укытучылар, педагогия уку йортлары студентлары өчен әһәмиятле (карагыз: И. К. Яковлев, А. М. Сохор. Методика и техника урока в школе, М., 1985).

Ләкин эшнең асылы «оештыру моментында» түгел. Дәрес үткәргәндә аның башында ук, гадәттә, укучыларның тиешле кәефе булмый; материалны гадәти истә калдыру, шуны кабатлау укытучының дәрестәге материалны коры гына сөйләп чыгуы, кайвакытта укучыларга тактсыз гына кисәтү ясавы — болар һәммәсе дә укучыларда тискәре эмоцияләр (үзенә бер төрле кәефсезлек) барлыкка китерә. Шундый хисләр исә укучыларның кызыксынып, теләк-дәрт белән укуына, акыл эшчәнлеген тулысынча эшкә җигәргә комачаулый. Укучыларның хисләр дөньясына кагылмый торган белемнәр инануларга әверелми, аларның дөньяга *карашын формалаштыруга* йогынты ясамый. Укыту процессын әнә шулай оештыра башлау яшь буынны тәрбияләүнең хәзерге, максатлары һәм бурычлары белән кискен каршылыкка керде. (Карагыз: Хәзерге дәрес. «Народное образование» журналы, 1985 ел, № 1 , 106 бит.)

Шуңа күрә иң мөһиме — дәреснең беренче минутыннан ук укучыларда тиешле эмоциональ халәт (кәеф) булдырырга, кызыксыну уятырга, ал арны киеренке эшчәнлеккә әзерләргә, дәресне өйрәнелә-үзләштерелә торган яңа материалдан, яңа күнекмәләрдән канәгатьләнү хисе алырлык итеп оештырырга кирәк. Башкача әйткәндә, дәрес укучыларны кызыксындырудан, дәрт уятудан, интенсив аралашудан, укытучының укучыларга тәрбияви йогынты ясавыннан башлансын. Беренче сүзләрдән үк материалны укучыларга аңлаешлы, аларның фикерләү дәртен һәм хисләрен уята алырлык проблемалы-эмоциональ бәян итү, проблемалы сораулар, мәсьәләләр бирү һәм аларны чишүне оештыру бик әһәмиятле.

Укучыларда эшкә дәрт-теләк уятуның, ягъни мотивациянең алымнары күп. Әй-, тик, башлангыч классларда укытучының дусларча елмаеп алуы, өлкән классларда җае туры килгәндә җиңелчә генә шаяртып, уен-көлке сүз әйтеп җибәрүе дә монда артык түгел. Укытучылар еш кына 2—3 минутлык мөстәкыйль эш эшләтәләр. Ул телдән яки язмача була. Проблемалы сорауны оста бирү, өйрәнелә торган мәсьәләнең *кыскача гына* тарихын сөйләү, шигъри кереш ясау, сәнгать чараларыннан файдалану, яхшы сочинение яки изложениене анализлау, укучылар ясаган әйбәт әйберләрне күрсәтү һ. б. шундый эшләр дә дәресне уңышлы башлап җибәрергә, белем һәм күнекмәләрне актуальләштерүне җиңеләйтергә ярдәм итә.

Беренче тип дәреснең иң мөһим функциясе — белемнәр системасы, эш-гамәл ысуллары һәм фәнни караш формалаштыру. Укыту-тәрбия эшенә яңача якын килү укучыларның диалектик фикерләвен үстерүне таләп итә. Хәзерге дидактикада нәкъ әнә шул диалектик фикерләүне дөньяга фәнни караш тәрбияләүнең нигезе һәм логикасы, зиһенгә алу һәм хәрәкәттә һәм үсештәге реаль чынбарлыкны аңлы рәвештә танып-белү методы итеп карарга кирәк. Шуңа күрә укучыларда диалектик (проблемалы) фикерләү диалектик каршылыкларны, ягъни уку-өйрәнү проблемаларын хәл итү ысулларын күрсәтү нигезендә генә формалаштырырга мөмкин (карагыз: М. И. Мах<мутов. Проблемное обучение. М., 1975).

Дәреснең өч төрле максатына («Совет мәктәбе» *журналының* 1987 елгы 1 нче санын карагыз) туры китереп, терәк белемнәрне һәм күнекмәләрне актуальл эштергәч (алда әйтеп үтелгәнчә, моның алымнары күп), укытучы яңа материалны өйрәнүне оештыруга күчә («ә хәзер яңа теманы өйрәнә башлыйбыз..^»). Бу күчеш кинәт яки салмак кына, укучыларга сизелмәслек тә (мәсьәләләр чишү, проблеманы хәл итү, тәҗрибә эшенең һ. б. дәвамы) булырга мөмкин.

2. Яңа төшенчәләр һәм эш-гамәл ысуллары формалаштыру (барлыкка китерү). Яңа төшенчәләр һәм эш-гамәл ысуллары формалаштыру — дәреснең иң мөһим өлеше, этабы, аның дидактик структурасының әһәмиятле компоненты ул. Бу этап ничек башлана? Гадәттә, укытучы яңа теманы яки дәреслекнең яңа

бүлеген өйрәнергә керешү турында әйтә. Ләкин укучыларның белемнәрен актуальләштергәндә үк, үзләре дә сизмәстән, яңа материалны өйрәнүгә күчә башлавы әйбәтрәк булып тора.

Дәреснең икенче этабы яңа материалның эчтәлеген тасвирлаудан яки аны сөйләп аңлатудан, яки күрсәтмә әсбап (шул исәптән кийофильм) күрсәтүдән, яисә танып-белү мәсьәләсе (бурычы) куюдан һәм укучыларның мөстәкыйль эшен оештырудан (язмача эш, мәсьәләләр чишү, тәҗрибә үткәрү, текстларны уку һәм анализлау һ. 6.) башланырга мөмкин.

Яңа материал, әгәр андагы төшенчәләр исбатлауны таләп итмәсә, билгеләмәләр ярдәмендә генә аңлатырлык булса, җыйнак итеп кенә тасвирлап бирелергә Мөмкин. Билгеләмәне әзер көенчә әйтергә һәм укучыларга аны истә калдырырга кушарга була. Мәсәлән, физика дәресендә: «Фарадей законы[4] нәрсәдән гыйбарәт?» — дигән сорау куйгач, укытучы: «Дәреслектә менә бол ай диелгән»,— дип, законның билгеләмәсен укый. Билгеләмәне укытучы ярдәмендә укучылар үзләре дә бирә ала, тик моның ' өчен башта проблемалы ситуация барлыкка китерергә, төшенчәнең билгеләмәсен табу-эзләү буенча укучыларның акыл эшчән леген оештырырга кирәк.

Әгәр уку материалында билгеләмәләр белән генә аңлатып булмаслык, ә танып-белү өчен барлык төп охшаш һәм аерымлык билгеләрен сурәтләүне таләп итә торган катлаулы төшенчәләр күп икән, ул чагында укытучы яңа материал-[ ны киң итеп тасвирлап сөйләргә мөмкин. Бу сөйләмнең шулай ук вариантлары бар: кайчакта укытучы, төшенчәнең барлык сыйфатлары турында фактлар һәм мисаллар китереп, үзе сөйли яки, проблемалы ситуацияләр барлыкка китереп (сорау биреп), төшенчәнең аерым сыйфатларын ачыкфу эшенә укучыларны җәлеп итә, үз фикерләрен тормыштан, фәнни-популяр әдәбияттан алынган мисаллар белән дәлилләргә куша һ. б. шундый эшләр оештыра.

Аңлату логика фәнендә фикерләүнең бер формасы булып исәпләнә һәм һәрвакыт чагыштыру, анализ, синтез, гомумиләштерү һ. б. шундый акыл (хәрәкәтен) *операцияләрен* үз эченә алв. Тасвирлаудан аермалы буларак, ул һәрчак ике өлештән: раслау һәм исбатлау өлешеннән тора. Беренче өлешенә раслау җөмләләре рәвешендә' әйтелгән барлык төшенчәләр керә- Мәсәлән: әгәр һәркем үз вазифасын намус белән үтәсә, ул вакытта илебезнең казанышлары тагын да югарырак була. Үз белемеңне даими рәвештә күтәргән очракта гына, тормыштан артта калмыйсың һ. б. Раслауларның һәммәсе дә аның дөрес, закончалыклы булуын нигезләү-дәлил-ләүне, исбат итүне сорый. Теге яки бу бәйләнешнең закончалыклы күренеш икәнлеген дәлилләгәндә исбат итүләрнең төрле системасы (индуктив һәм дедуктив, тәҗрибә-эксперименталь һәм теоретик, логик һәм тарихи, математик һәм сүз белән сөйләп-логик) кулланыла.

Объектлар, күренешләр яки төшенчәләрне тасвирлап биргәннән, аңлатканнан соң ук, укытучы аларны ничек куллану яки үзгәртеп кору турында рекомендацияләр бирә. Шул рәвешчә, укытучының бәян итүе күрсәтмә бирү характерын ала, ул күрсәтмәләрдә тасвирланган, аңлатылган төшенчәләрне, объектлар яки күренешләрне үзгәртеп кору буенча практик эшчәнлекне ничек оештыруның принциплары, кагыйдәләре яки рекомендацияләре чагылыш таба.

Әгәр раслаулар һәм исбатлаулар укытучы тарафыннан гына башкарылса, мондый укыту укучыларның акыл сәләтен үстерми, дибез, чөнки алар үрнәк буенча гына эш итәргә өйрәнә-гадәтләнәләр (чынбарлыкта ул, әлбәттә, күпмедер үсә). Әгәр укытучы укучыларны раслаулы җөмләләр төзүгә җәлеп итсә (мәсәлән, ул үзе дәрестә: «Әгәр җәмгыять антагонистик сыйныфлардан торса, ул чакта...-нәрсә булырга мөмкин?»— ди, укучыларны сыйнфый көрәшнең котылгысыз булуы турында уйланырга этәрә), ул чакта ал арның танып-белү эшчәнлеге һәм укытучы сөйләгәнне тыңлау активлыгы арта. Әгәр раслауларны укытучы үзе әйтеп, укучыларга шуларны дәлилләргә, исбатларга кушса, фикерләү эшчәнлеге тагын да ныграк активлаша. Моның өчен ул проблемалы ситуация китереп чыгара яки үзе проблема куя, укучыларга эзләнү эшен фараз итүләрдән башларга куша (бусы, әлбәттә, эшне проблема куюдан башлауга караганда,алар өчен җиңелрәк).

Яңа материалны .үзләштерү буенча укучыларның мөстәкыйль эшләрен оештыру аларның акыл сәләтен үстерүдә бик әһәмиятле роль уйный. Әгәр яңа материал логик эзлеклелектә булса (аның иң мөһим законнары — сәбәп һәм нәтиҗә бәйләнешләре, *аналогия,* индукция һәм дедукция тиешле тәртипкә китерелсә) һәм фактик материалны, аны өйрәнү шартларын, ориентирларын, күзәтүләрнең нәтиҗәләрен бирсә, ул чакта укучылар мөстәкыйль рәвештә:

— объектлар һәм күренешләрне (төшенчәләрне) тасвирлый, билгеләмәләрне әйтә-чыгара һәм хикәяләр төзи беләләр;

— объектлар һәм күренешләрне (төшенчәләрне) аңлата, законнарны, теоремаларны, үзлекләрне үзләре әйтә-китереп чыгара;

— принципларны, кагыйдәләрне әйтә-чыгара һәм аларны практикада куллана алалар.

Фәнни әдәбиятта укучыларның мөстәкыйль эшләренең берничә классификациясе бар. Практикада куллану өчен И. И. Малкин классификациясе (башкару, ярым иҗади, иҗади һ. б. шундый характердагы мөстәкыйль эшләр) һәм П. И. Пидкасистый классификациясе уңышлырак булып тора. Соңгысы мөстәкыйль эшләрнең дүрт тибын күрсәтә. Кыскама гына әйткәндә, алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

— шушы предметны өйрәнгәндә турыдан-туры аналогик яки элегрәк шуңа аналогик булган предмет эчендәге ситуациядән файдаланып, үрнәк буенча мәсьәләләр эшләү (укытучы ничек эшләргә икәнлеген күрсәткән яки дәреслектә чишү үрнәкләре җентекләп аңлатылган мисал һәм мәсьәләләр чишү);

— башка предметларны өйрәнгәндә турыдан-туры аналогик яки элегрәк шуңа аналогик булган предметара ситуациядән файдаланып, үрнәк буенча мәсьәләләр эшләү (беренче үрнәктән аермалы буларак, биредә башка предметлар буенча мәсьәләләр чишү ысулларын белү таләп ителә);

— мәгълүм эш ысулларын гадәти булмаган шартларда предмет эчендәге яки предметара проблемалы ситуацияне хәл иткәндә реконструктив-вариатив рәвештә файдалану (мәсәлән, физикадан мәсьәләләр чишкәндә математик мәсьәләләрне чишү ысулларын куллану һ. б.);

— предметның үз эчендә һәм предметара фәнни-тикшеренү характерындагы мөстәкыйль эшләр (максатны, эшнең эчтәлеген укучылар үзләре билгелиләр, мәсьәләләрне чишүнең яңа ысулларын табалар һ. б.).

Мөстәкыйль эшләрнең барлык типлары һәм төрләре дәреснең өч максатыннан чыгып оештырыла, алар аның өч этабында да булырга мөмкин, ләкин барыннан да бигрәк яңа төшенчәләргә һәм эш-гамәлләрне үтәү ысулларына өйрәткәндә кулланыла.

Дәреснең икенче этабы (ул — дидактик структураның икенче компоненты булып тора) еш кына проблемалы ситуация барлыкка китерүдән, проблемалы сораулар куюдан башлана. Терәк белемнәр белән яңа төшенчәләр арасында, шулай ук предметның-үз эчендә һәм предметара бәйләнешләр урнаштырыла, дәреснең тиешле темпта узуына, анда җитди эш атмосферасы (тиешле кәеф) булдыруга әһәмият бирелә. Болар һәммәсе дә яңа материалны өзлексез белем системасы рәвешендә үзләштерергә, укытуда дәвамчанлылык принцибын тормышка ашырырга ярдәм итә. Предметара бәйләнешләр, дәреснең белемнәрне актуальләштерү этабыннан башлап, йомгаклау өлешенә кадәр һәм төрле предметлар буенча дәресләр системасының ахырынача «үтәли» дәвам иттерелә.

Гомумән, дәреснең яңа теориясе теге яки бу предмет (физика, химия һ. б.) цикләрендә генә түгел, ә төрле фән нитезләре буенча укучыларда белемнәр, системасы булдыруга зур әһәмият бирә. Җитештерүчән хезмәт белән бәйләнгән фәнни һәм политехник белемнәр системасы гына табигать, җәмгыять һәм фикерләү, дөньяны танып-белү турында тулы бер күзаллау булдыруга ярдәм итә. Башкача әйткәндә, дөньяның физик, химик һ. б. шундый үзлекләре турында өзек-өзек белемнәр түгел, ә белемнәр, күнекмәләр һәм

эш-гамәлләрнең бердәмлеге генә шәхесне һәрьяклап үстерү, аның дөньяга фәнни карашын формалаштыруның нигезе була ала.

Белемнәрне практикада, эштә куллану — дәрес структурасының өченче компоненты; башка компонентлар кебек, ул да укыту эшендә зур әһәмияткә ия. Традицион дәреснең кимчелекләреннән берсе — белемнәрнең практикада кулланылмавы. Укучылар кагыйдәләрне, законнарны беләләр, әмма еш кына аларны практикада куллана алмыйлар; теореманы беләләр, аны исбатларга кыенсыналар; күренешләрне, фактларны истә калдыралар, әмма аларны гомумиләштерергә яки конкретлаштырырга читенсенәләр һ. б.

Мәгълүм ки, теләсә нинди белем, әгәр ул инануга әверелмәсә, эшли белүгә һәм эш-гамәлгә ярдәм итмәсә, «коры» белем булып кына кала. Бу әве- < релеш белемнәрне практикада кулланганда гына уңышлы бара. Беренче тип ( дәресләрдә белемнәрне гамәлгә кую, I ягъни практикада куллануга укучылар яңа төшенчәләр һәм эиьгамәл ысулларын үзләштергәч керешелә, һәм ул озак вакыт алмый. Белемнәрне камилләштерү, гомумиләштерү һәм аларга контроль ясау дәресләрендә белемне куллану дәреснең төп компоненты; (этабы) булып тора. Анда белемнәрне; камилләштерү, укучыларның танып-белү осталыгын һәм күнекмәләрен ныгыту буенча мөстәкыйль эшләр . оештырыла.

Дәрес структурасының дидактик, белемнәрне гамәлгә кую — практикада куллану компоненты да берничә методик элементны үз эченә ала. Анда күнегүләр, практик эшләр өстенлек алып тора. Мәсәлән, дәреснең икенче этабында текстка логик анализ ясау буенча мөстәкыйль эшләр өченче этапта алгоритм, үрнәк буенча эшкә күчә — текстны анализлау күнекмәсен ныгыту эше алып барыла. Проблемаларны хәл итү проблемасыз мәсьәләләрне чишү белән алмашына (җае туры килсә, укытучы проблемалы мәсьәләләрне дә тәкъдим итәргә мөмкин). Белемнәрнең ни[чек үзләштерелүенә контрольдә, дәрестә укучының эшенә билге кую, өйгә эш бирү дә шушы өченче этапта (дәреснең азаккы өлешендә) була.

Беренче мәкаләдә әйтелгәнчә, дәреснең дидактик структурасы өч өлештән (компоненттан) гыйбарәт, һәр компонент методик яктан үзе тагын берничә ваграк өлештән (элементтан) тора; шул элементлар конкрет алым һәм ысуллар җыелмасыннан гыйбарәт.

Контрольне укытучы дәреснең һәр этабында игътибар үзәгендә тота; укучыларның яңа материалны ничек үзләштерүен, мөстәкыйль эшләрне ничек үтәвен, проблемаларны ничек хәл итүен күзәтә; болар белән генә чикләнмичә, проблемалы сорауларның ни дәрәҗәдә катлаулы булуын, укучыларның аларны мөстәкыйль рәвештә хәл итә, фараз-гипотезаларны дәлилли алуын һ. б. тикшерә; белемнәр системасының һәм дөньяга карашның ничек формалашуын тикшерүгә аеруча әһәмият бирә.

Өйгә эш бирү мәсьәләсе һәрчак бәхәсләр китереп чыгара иде, чөнки ул укучыларга артык эш йөкләү белән дә бәйле. Элегрәк өйгә эшне дәрес ахырында гына бирергә тәкъдим ителә иде. Укытуны активлаштыру тәҗрибәсе күрсәткәнчә (мәсәлән, Липецк өлкәсе һәм Татарстан АССР мәктәпләрендә), өйгә эшне дәреснең теләсә кайсы этабында, хәтта башында да бирергә яки бөтенләй бирмәскә мөмкин (мәсәлән, Е. Н. Ильин һәм И. Х. Бикбулатова тәҗрибәсендә).

Ләкин, кагыйдә буларак, укытучылар өйгә эшне дәрес ахырында бирәләр. Бу өйгә эшнең күләмен билгеләүгә, укучыларның (яки аерым төркемнең) яңа материалны ничек үзләштерүенә бәйләнгән. Галимнәр өйгә бирелгән эштә дүрт компонент (белемнәрне кабатлау, аларны куллана белү күнегүләре эшләү, иҗади эшләр башкару, белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру) булган очракны иң яхшы вариант дип саныйлар. (Карагыз: Н. М. Скаткин, И. Я. Лернер. Современный урок. «Народное образование», 1985, № 1.) Әлбәттә, бу компонентлар барысы да бер дәрестә булмаска, алар бергә кушылырга, бу бирем һәр компонентны да уз эченә алган булырга һ. б. мөмкин. Укучыларга өйгә эш бирүгә һәр очракта да укытучы иҗади якын килергә тиеш.